

Инсар районы Казеевка авылындагы “МолАгро” авыл хужалыгы предприятиесе эшләп килә. Ул торле авыл хужалыгы культуралары һәм сот терлекчелеген vстерv белән шогыльләнә.
Мордовиядә сот фермалары һәм комплекслары хезмәткәрләренен хезмәт ярышында 2 урын алган “МолАгро” авыл хужалыгы предприятиесендә торле милләт кешеләре һәм торле районнарда (Инсар, Кадошкино, Рузаевка) яшәvчеләр алга алып бара. Шулар исәбендә татар милләтле Кадошкино районы унган, тырыш хатын-кызлары хезмәт итә. Комплекснын башлангыч чорыннан ук Большие Поляны авылыннан Альмяшева Ирина, аннары Рәшидә Зайкина, Рима Тумпарова, Света Асаинова (фотода), Марина Долотказина, Латышовка авылыннан Гvзәл Демакова эшлиләр.      Комплекс белән танышып алабыз. Әйтеп киттем инде: сот комплексы заманча жиһазландырылган. Кеше факторын олешчә читләтеп, югары сыйфатлы продукция алырга момкинлек бирә. Узган ел йомгаклары буенча коненә сот савымы бер сыерга 11 тонна. Мондый кvрсәткечләргә туклануга грамоталы якын килv хисабына да ирешелгән. Савылган сотләре “Сармич” Инсар предприятиесендә сырлар житештерvгә китә. Бvгенге кондә сот комплексы момкинлекләре сыр, май һәм башка продукция житештерv очен сыр комбинатын 20 процентан артык сот белән тәэмин итәргә момкинлек бирә.
Сот юнәлеше стратегик һәм заманча сот комплексы тозелеше нәтижәсендә унышлы vсеш ала. Бирeдә 150 артык кеше югары тvләvле эш белән тәэмин ителә. Сvз унаеннан, быелгы сонгы мәгълvматлар буенча сот комплексы хезмәткәрләренен уртача айлык хезмәт хакы 48-50 мен сум.
Комплекстагы сыер савучылар оч смена эшлиләр. Аларга хезмәт шартлары тудырылган. Үзләрен предприятие транспорты тvләvсез килеп ала, озатып куя, смена вакытында тvләvсез ашаталар, таләп ителгән хезмәткәрләрен яшәv урыны белән тәэмин итәләр. Белгәнебезчә, сыер саву эше кvп коч таләп итә. Башта саву аппаратларын әзерләргә, саву стаканнарын кидерергә һәм салдырырга кирәк. Бер сvз белән әйткәндә, мәшәкать житәрлек. Эш урынын, саву механизмнарын чисталыкта тоту да зарур. Сыер савучыларнын эшен бvген заманча жиһазлар шактый жинеләйтә. Әмма барыбер бу хезмәттә физик коч тә, ныклы сәламәтлек һәм тvземлек тә кирәк. Һәм, әлбәттә, малларны ярату да. Кадошкино районы Насакан Потьма авылында яшәvче Света Асаинова әнә шул сыйфатларга ия. Сыерларны оч тапкыр сава ул, коненә ун да, ике генә дә бозау да кабул итә; берникадәр вакыт бозауларны карый да. Менә шулкадәр торле хезмәттә ул. Шул рәвешле комплекста тик vзләре vрчеткән мал-туар: бозаудан сыер vстерәләр һәм аннары алардан сот савып алалар. Бар эшләре предприятиенен терлекчелек буенча директор урынбасары Александр Цыганов житәкчелегендә башкарыла.
Үз эшенә шулкадәр бирелеп, чын кvнелдән тырышып һәм яратып хезмәт итvче кешеләргә ихластан сокланам. Иса, Латышовка сыер савучылары да шундыйлар. Алар арасында Света Асаинова (югарыда санап киткән тырыш татар милләтле кызларыбыз турында киләсе саннарда укырсыз) да эшен намус белән башкара, кушканнарны жиренә

житкереп vти. Бик жаваплы, тырыш кеше ул. Тормыш иптәше Рәшит белән ике бала - Регина белән Ремирны тәрбияләп vстерделәр, бvген Голназ белән Азамат оныклары шатландыра аларны.

**Наилә НАСЫРОВА**